РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11.2020 № 953

2021 елга Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 ст. 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга Нурлат муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга.

2. Нурлат муниципаль районының "Финанс-бюджет палатасы" МКУна әлеге карарның 1 пункты һәм «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 18.11.2020 ел,
№ 953 карары белән расланды

Нурлат муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Урнашу территориясе | Бер кешегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Интернат при общеобразовательнойорганизации | шәһәр җирлеге | 92851 |
| | авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139227 |
| | авыл җирлеге | 143701 |